Сергей Михалков


Ө[illegible]
ДУҢГЫЗ БАЛАСЫ

К. Ротов рәсемнәре

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ



Сергей Михалков



Өч дуңгыз баласы

Инглиз әкияте буенча

К. Ротов рәсемнәре

Татарстан китап нәшрияты Казан 1967

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

Сергей Владимирович Михалков

Три поросёнка. Государственное издательство детской литературы Министерства просвещения РСФСР. Москва. 1959.

Сергей Владимирович Михалков

Р 2
М 69 Өч дуңгыз баласы. Гарәфи Хәсәнов тәрҗемәсе. Татарстан китап нәшрияты. Казан. 1967.

32 бит. 40 000 экз. 27 тиен.

Балалар!

Сезнең алда борынгы инглиз экиятенә ияреп язылган бик кызыклы китап. Аның матур-матур рәсемнәрен карарсыз, рәсемнәрен әйбәтрәк аңлар өчен, экиятнең үзен дә укырсыз. Бу экият сезгә ошап китәр дә, сез аны кабат-кабат укырсыз, шигырьләрен яттан өйрәнерсез.

7—6—1
288—66 М

Сергей Владимирович Михалков

ТРИ ПОРОСЁНКА

(на татарском языке)

Редакторы К. Миңлебаев

Художество редакторы Н. Әбделмәнова


Техник редакторы С. Әхмәтҗанова

Корректоры М. Мирсалихова

Наборга бирелде 28/II-1966 ел. Басарга кул куелды 6/II-1967 ел. 100 гр. офсет кәгазе. 60×90[1]/[8]. Учетн.-изд. табагы 3,81. Якынча басма табагы 4,0. Заказ № Н-324. Тираж 40 000. Бәясе 27 тиен.

Татарстан китап нәшрияты
Казан, Бауман ур., 19

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман ур., 19



Булган, ди, өч дуңгыз баласы. Өчесе бертуган булганга, алар өчесе дә бер үк зурлыкта, өчесе дә түм-түгәрәк, өчесе дә алсу тәнлеләр икән, ди. Койрыкларына хәтле бер төсле икән, ди.

Аларның хәтта исемнәре дә бер-беренә охшаш була. Дуңгыз балаларының берсен — Ниф-Ниф, икенчесен — Нуф-Нуф, өченчесен Наф-Наф дип йөртә иделәр. Алар җәйнең



җәй буе яшел үләндә мәтәлчек атып уйныйлар, рәхәтләнеп кояшта кызыналар, болганчык суларда ауныйлар.

Бервакытны көз килеп җитә.

Кояш та инде алай каты кыздырмый, агачлар саргая, болытлар куера башлый.

Көннәрдән бер көнне Наф-Наф үзенең туганнарына:

— Кыш турында да уйларга вакыттыр инде. Салкын җилекләргә үтә. Авырып китмик тагы, — ди. — Әйдәгез, зур гына бер йорт салыйк та кышны шунда бергә-бергә уздырыйк, — ди.

Туганнарының гына эшкә тотынасылары килми. Җир казып, таш ташып йөргәнче, җәйнең соңгы көннәрендә болын буйлап тик йөрүне, мәтәлчек атуны артыграк күрәләр алар.

— Өлгерербез әле! — ди Ниф-Ниф. — Кышка хәтле байтак вакыт бар әле. Күңел ачып калыйк ичмасам! — ди дә мәтәлчек атына.

Нуф-Нуф исә пычрак суга кереп сузылып ята:

— Кирәк булса, йортны салам мин аны! Хәзергә уйныйм әле.


— Ярар, — ди Наф-Наф, — сез алайса теләсәгез нишләгез, мин салам. Сезне көтеп тора алмыйм.




Көннәр үткән саен, салкынайта бара. Ниф-Ниф белән Нуф-Нуф кына пошынмыйлар. Эш турында алар уйлап та карамыйлар. Иртәдән кичкә хәтле аркылыны буйга алып салмыйлар. Бар белгәннәре дуңгыз балалары уенын уйнау да сикеренү, я булмаса мәтәлчәк атыну була.

— Бүгенгә күңел ачыйк та иртәгә иртән үк эшкә тотынырбыз,— диләр алар. Ә иртәгесен шул ук сүзне кабатлыйлар.

Юл буендагы суларны юка боз каплап алгач кына, бу ике туган эшкә керешәләр.






„Өйне саламнан гына әмәллим әле! Мәшәкате дә аз булыр, тизрәк тә булыр“, — дип уйлый Ниф-Ниф. Беркем белән киңәш-табыш итеп тормыйча, тота да шулай эшли. Кичкә хәтле өен салып та бетерә.

Соңгы уч саламын түбәгә җәеп куя да, эшеннән канәгатьләнеп, күңелле итеп җырлап җибәрә:

Дөньяда юк мондый өй,
Мондый өй, мондый өй!
Көлеп тора минем өй,
Минем өй, минем өй!



Шулай җырлый-җырлый, ул Нуф-Нуф янына китә.

Нуф-Нуф та шул тирәдәрәк кенә өй салып ята иде.

Өй салудай күңелсез эштән ул ничек кенә булса да тизрәк котылырга тырыша. Башта ул йортны саламнан гына салмакчы иде. Ләкин андый йортта кышын суык булудан курка. „Чыбык-чабыклардан салсаң, ныграк та булыр, җылырак та булыр“, — дип уйлый ул.


Җиргә казыклар кага да чыбык-чабыктан читән кебегрәк бер нәрсә корыштырып куя. Түбәсенә корыган яфраклар ташлый. Кичкә хәтле өен салып та бетерә.


Куанычыннан ул өен берничә тапкыр әйләнеп чыга да җырлап җибәрә:

Йортым минем бер дигән,
Янадыр ул, ныктыр ул!
Су үтмәс, яшен тимәс,
Башка андый юктыр шул!

Ул җырлап та бетерми, куаклар арасыннан Ниф-Ниф атылып килеп чыга.

— Менә син дә өйле булдың! Бу эшне бик җиңел башкарып чыгарбыз, дип әйткән идем бит! Менә хәзер икебез дә буш, теләсәк нишлибез!






— Әйдә Наф-Наф янына барыйк әле. Нинди йорт сала икән, карыйк әле. Күптән күргән дә юк үзен, — ди Нуф-Нуф.

— Барсак барыйк, — ди Ниф-Ниф.

Бүтән берни турында да кайгыртасы юкка шатланып, икесе дә куаклар арасына кереп китәләр.

Наф-Наф берничә көннән бирле өй салу эшенә чумган иде. Әллә никадәрле таш ташып, балчык изеп куйган да өен ашыкмыйча гына, бик ныклап, җил-яңгырдан һәм суыктан сакларлык итеп төзеп ята иде.



Күрше урманнан бүре килеп кермәгәе дип, өенә авыр имән ишек куйган, аңа бикләвеч ясаган иде.

Ниф-Ниф белән Нуф-Нуф аның эшләп яткан чагына туры киләләр.

Исләре китеп, икесе дә беравыздан:

— Син ни кыландырасың болай? — дип кычкырып җибәрәләр. — Дуңгыз баласы йортымы, әллә бер ныгытмамы бу?

Наф-Наф, эшен бүлми генә:

— Дуңгыз баласы өе ныгытма булырга тиеш! — дип тыныч кына җавап бирә.

— Берәрсе белән сугышырга җыенмыйсыңдыр ич? — дип мыркылдый Ниф-Ниф һәм Нуф-Нуфка күз кысып куя.

Бу сүздән икесе дә бөтен болынны яңгыратып көлешәләр, мыркылдашалар.

Наф-Наф исә, авыз эченнән генә җырлый-җырлый, йортының таш стенасын өя дә өя:

Мин, әлбәттә, бик зирәк,
Бик зирәк, бик зирәк!
Йорт бары таштан кирәк,
Бик кирәк, бик кирәк!
Булса да бик хәйләкәр,
Бик усал, коточкыч,
Бу ишекне ачалмас
Бер ерткыч, бер ерткыч!

— Ул нинди ерткыч тагы? — дип сорап куя Ниф-Ниф Нуф-Нуфтан.

— Ул нинди ерткыч тагы? — дип сорап куя Нуф-Нуф Наф-Нафтан.

— Нинди булсын — бүре! — дип җавап бирә Наф-Наф һәм тагын бер кирпеч китереп сала.

— Карасана, ул бүредән курка! — ди Ниф-Ниф.

— Бүре ашар дип курка! — ди Нуф-Нуф.

Туганнар тагын да ныграк көләләр, мыркылдыйлар.

— Монда нинди бүре булсын? — ди Ниф-Ниф.

Нуф-Нуф та сүзсез калмый:

— Монда берниндн бүре дә юк! Куркак ул!

Шуннан алар биешә-биешә җырлап җибәрәләр:

Куркытмый безне бүре,
Соры бүре, карт бүре!
Кайда син, ахмак бүре,
Соры бүре, карт бүре?

Алар Наф-Нафны үчекләмәкче булалар да соң, тегесе әйләнеп тә карамый.

— Киттек, Нуф-Нуф, — ди моны күреп Ниф-Ниф, — монда безгә бер эш тә юк!

Шулай диләр дә ике батыр күңел ачып йөрергә китәләр. Бии-бии, җырлый-җырлый баралар, хәтта әле урманга кергәч тә туктый белмиләр. Бу тавышка нарат астында йоклап яткан бүре уянып китә. Үзе ач, үзе бик усал икән бүре.



— Бу нинди тавыш? — дип ачу белән мыгырданып куя ул. Аннары ахмак дуңгыз балаларының чыр-чуы килгән якка торып чаба.

Бүрене рәсемдә генә күргән Ниф-Ниф:

— Каян килеп монда бүре булсын? — дип сөйләнеп тора иде.


Нуф-Нуфның да тере бүрене әле күргәне юк иде.


— Борыныннан эләктереп алсак, күрмәгәнен күрер! — дип сөйләнә ул.

— Егып кына калдырмабыз, бәйләп салырбыз да менә болай, менә болай таптарбыз үзен! — ди Ниф-Ниф һәм тап-тап күрсәтә.

Туганнарның кәефләре тагын да ныграк күтәрелә, һәм алар кычкырып җырлап җибәрәләр:

Куркытмый безне бүре,
Соры бүре, карт бүре!
Кайда син, ахмак бүре,
Соры бүре, карт бүре?





Күзләрен ачыбрак карасалар — алларында чын бүре!

Зур агач артына поскан да тик тора. Кыяфәте коточкыч, күзләре зәһәр елтырый, тешләре ыржайган. Аны күргәч, Ниф-Ниф белән Нуф-Нуфның тәннәре чымырдап куя, нәни койрыклары дер-дер калтырый. Бичара дуңгыз балалары баскан урыннарында катып калалар.

Бүре сикерергә хәзерләнә, тешләрен шак-шык китерә, уң күзен акайта. Шул чак дуңгыз балалары аңга киләләр дә чиный-чиный йөгерәләр.

Моңарчы аларның гомерләрендә дә болай тиз йөгергәннәре булмый.

Үкчәләрен ялтыратып, тузан болыты күтәреп, һәркайсы үз өенә чаба.




Ниф-Ниф салам өенә элегрәк кайтып җитә һәм бүренең борын төбендә ишеген ябып өлгерә.

— Хәзер үк ишегеңне ач! Юкса ватып керәм! — ди бүре.

— Юк, ачмыйм, — ди Ниф-Ниф.

Ишек аркылы явыз ерткычның сулыш алуы ишетелә.

— Хәзер үк ишегеңне ач! — дип кабатлый бүре. — Юкса, йортыңны өреп очырам!



Ниф-Ниф куркудан ни дип тә җавап бирә алмый.

Шунда бүре өрергә тотына: „Өф-ф-фе-е-е!“

Өй түбәсеннән салам оча, стеналар дер селкенә.

Бүре яңадан тирән итеп сулыш ала да яңадан өреп җибәрә: „Өф-ф-фе-е-е-е!“

Бүре өченче тапкыр өргәч инде, көчле өермә килеп бәрелгәндәй, төрле якка очып тарала өй.

Бүре дуңгыз баласының түм-түгәрәк нәни борыны төбендә үк тешен шыкырдатып куя. Ләкин Ниф-Ниф читкә

тайпылып өлгерә һәм йөгереп китә. Бер минут эчендә Нуф-Нуф янына килеп җитә.


Ике туган тиз-тиз ишекне бикләп куялар. Шундук бүре тавышы ишетелә:


— Икегезне дә тотып ашыйм болай булгач!

Ниф-Ниф белән Нуф-Нуф куркышып бер-беренә карап алалар. Тик инде бүре, бик нык арыганлыктан, хәйлә белән эш итәргә була.

Өйдәгеләр ишетсен дип, ул юри кычкырып сөйләнә:

— Юк, юк, алай итмим әле. Мин бу бетерешкән дуңгыз балаларын ашамыйм әле. Өемә кайтыйм әле!





— Ишеттеңме? — дип сорый Ниф-Ниф Нуф-Нуфтан. — Ул безне ашамыйм ди ич! Без бетерешкән икәнбез!

— Бик яхшы! — ди Нуф-Нуф. Шундук калтыравыннан да туктый.

Туганнарның күңеле күтәрелеп китә, һәм алар, берни булмагандай, җырлап җибәрәләр:

Куркытмый безне бүре,
Соры бүре, карт бүре!
Кайда син, ахмак бүре,
Соры бүре, карт бүре?



Ә бүренең китәргә исәбе дә юк. Ул бер почмакка яшеренә генә. Бик көлке тоела аңа. Шаркылдап көлеп җибәрмичә көчкә түзеп тора. Бу ахмак дуңгыз балаларын тәки алдады бит!

Дуңгыз балалары тәмам тынычлангач, бүре сарык тиресе ала да посып кына өйгә якынлаша. Ишек төбенә җиткәч, сарык тиресен бөркәнә дә әкрен генә шакып карый.

Шакыганны ишеткәч, Ниф-Ниф белән Нуф-Нуф куркуга төшәләр.

— Кем бар? — диләр. Үзләренең нәни койрыклары тагын дер-дер калтырарга тотына.

— Бу — ми-и-ин — бер бичара сарык! — дип чинап җибәрә бүре нәзек кенә тавыш белән. — Мин көтүдән аерылып калдым, бик арыдым. Кунарга кертмәссез микән?

— Кертергәме? — дип сорап куя киң күңелле Ниф-Ниф туганыннан.

— Сарыкны кертергә була! — дип ризалык бирә Нуф-Нуф. — Сарык — бүре түгел инде ул.

Дуңгыз балалары сарыкка дип ишекне ачсалар — әлеге дә баягы шул ыржайган тешле бүре! Туганнар шап итеп ишекне ябалар. Ерткыч бәреп кермәсен өчен, ишекне бар куәтләренә терәп торалар.





Бүренең ачуы чыга. Хәйләли алмады бит шул дуңгыз балаларын! Ул өстендәге сарык тиресен ташлый да:

— Бирермен әле кирәгегезне! Өегезнең хәзер көлен күккә очырам! — ди.

Шулай ди дә өрергә тотына. Йорт бераз кыйшая башлый. Бүре тагын икенче кат, өченче кат, дүртенче кат өрә. Түбәдәге яфраклар очып-очып төшәләр, стеналар селкенә, тик шулай да өй әле һаман җимерелми иде.

Бүре бишенче кат өргәч кенә, өй чайкалып куя һәм җимерелеп тә төшә. Шул җимерекләр арасында тик бер ишек кенә утырып кала.






Дуңгыз балалары, котлары алынып, йөгерешеп китәләр. Куркудан алар аяксыз калалар, һәрбер кыллары дерелди, танаулары кибә. Ике туган барлык көчләренә Наф-Наф өенә таба йөгерә.

Бүре зур-зур алдыртып сикерә-сикерә артларыннан җитә язып килә. Ул бер тапкыр чак кына Ниф-Нифның сыйрагыннан эләктереп алмый. Ниф-Ниф тагын да катырак чаба башлый.

Бүре дә кызулый төшә. „Бу юлы ычкындырмыйм инде!“ — дип уйлый бүре.

Ләкин ул бәлагә очрый.




Дуңгыз балалары зур бер алмагач яныннан выжт итеп узып китәләр. Бүре исә читкә тайпылып өлгерә алмый, очып килгән мәлгә шул алмагачка бәрелә. Шабырдап алмалары коела. Бер бик каты алма аның маңгаена килеп төшә дә маңгаен шештереп чыгара.


Ул арада Ниф-Ниф белән Нуф-Нуф, ярым үле, ярым тере хәлдә, Наф-Наф өенә йөгерешеп килеп җитәләр.

Туганнары аларны тиз генә өйгә кертә. Бу бичара дуңгыз балалары куркудан сүз дә әйтә алмас булганнар иде.

Алар, дәшми-тынмый караваt астына ташланып, шунда посышып калалар. Наф-Наф аларны бүре куганын шундук аңлап ала. Ләкин аның таш йортында куркырга урын булмый. Ул тиз генә ишекнең бикләвечен этеп куя да, урындыкка утырып, кычкырып җырлап җибәрә:

Булса да бик хәйләкәр,
Бик усал, коточкыч,
Бу ишекне ачалмас
Бер ерткыч, бер ерткыч!





Нәкъ шул чакта ишек шакыйлар.

— Кем ул анда? — дип сорый Наф-Наф, тыныч кына.

Бүренең тупас тавышы ишетелә:

— Күп телеңә салынма, ач тизрәк!

Наф-Нафның исе дә китми.

— Ачмый торсын әле! Ачкан диярләр! — дип җавап кайтара ул.

— Әһә, алай икән! Алайса чыдап кына торыгыз! Мин хәзер өчегезне дә тотып ашыйм!

Наф-Наф утырган урыныннан да кузгалмый.

— Ашап кара, — ди. Бу нык таш йортта аның үзенә дә, туганнарына да куркырга урын булмавын ул яхшы белә.


Шунда инде бүре тирәнрәк итеп сулыш ала да бар көченә өреп тә җибәрә.

Ләкин ул күпме генә өрмәсен, нәни генә бер таш та үз урыныннан купмый.

Бүре көчәнүдән агарынып-күгәренеп бетә.

Йорт чыннан да ныгытма шикелле тора. Шуннан бүре ишекне дөбердәтә башлый. Тик ишек тә бирешми.

Бүре ачуыннан өйнең стенасын тырный, аның ташларын кимереп карый. Тик ул тырнакларын сындырып бетерә, тешләрен тәмам эштән чыгара. Бу усал ач бүренең, кайтып китми, бүтән чарасы калмый.



Ләкин шул чагында бүренең күзе морҗага төшә. Куанычы эченә сыймый.


— Әһә! Тотам да морҗадан төшәм!

Ул сакланып кына түбәгә менә дә бераз колак салып тыңлап тора. Өй эче тып-тын.

„Мин бүген барыбер ашыйм аларны!“ —дип уйлый бүре һәм, иреннәрен ялаштыргалап, морҗага якынлаша.

Ләкин ул морҗадан төшә башлауга, дуңгыз балалары аның кыштырдаганын ишетәләр. Казан капкачына корым да коела башлагач, зирәк Наф-Наф эшне шундук сизеп ала.





Ул тиз генә кайнап торган казан янына ташлана һәм казанның капкачын ачып куя.


— Менә хәзер рәхим итегез! — ди Наф-Наф һәм туганнарына күз кыса.

Ниф-Ниф белән Нуф-Нуф ул арада тынычланып өлгерәләр һәм, елмаешып, үзләренең акыллы, батыр туганнарына сокланып карап торалар.

Дуңгыз балаларына озак көтәргә туры килми.

Корымга буялып беткән бүре кайнап торган суга шапылдап килеп төшә.

Бөтен тәннәрен куырып ала кайнар су.



Күзләре атылып чыга бүренең. Каты үкереп җибәрә. Морҗадан ничек кире чыгуын да, түбәдән ничек җиргә төшүен дә сизми кала. Койрыгын кысып кына, бикле ишек турысыннан урманга чабып уза.

Ә өч туган, өч нәни дуңгыз баласы, аның артыннан карап калалар. Бу явызны акылга утыртуларына куанышалар.

Ә бераздан күңелле җырларын җырлап җибәрәләр:



Дөньяда юк мондый өй,
Мондый өй, мондый өй!
Көлеп тора безнең өй,
Безнең өй, безнең өй!

Булса да бик хәйләкәр,
Бик усал, коточкыч,
Бу ишекне ачалмас
Бер ерткыч, бер ерткыч!

Кирәген нык биргәнгә,
Бүрегә биргәнгә,
Урманның бу тирәгә,
Килмәс бу тирәгә!

Менә шул хәлдән соң бу өч туган бергә-бергә яши башлыйлар.

Өч нәни дуңгыз баласы — Ниф-Ниф, Нуф-Нуф һәм Наф-Наф турында безнең бар белгәннәр менә шушы инде.

